Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Нырты авыл җирлеге Советы

КАРАР

31 июль, 2024 ел № 17

**Нырты авыл җирлеге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Нырты авыл җирлеге Уставы нигезендә Нырты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Нырты авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Кукмара муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Нырты авыл җирлеге Башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Нырты авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында Нырты авыл җирлеге Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нырты авыл җирлеге Советының Икътисадый сәясәт һәм бюджет комиссиясенә йөкләргә.

Нырты авылы җирлек башлыгы Т.А.Котдусов